Муниципальное бюджетное дошкольное
образовательное учреждение
«Детский сад присмотра и оздоровления детей №14
«Подсолнушек» Чистопольского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
муниципаль үзидәрәле мәктәпкәчә белем бирү
учреждениесе “14 номерлы балаларны карау һәм
сәламәтләндерүче балалар бакчасы “Көнбагыш”

**Утверждено и введено в действие**
приказ № 84 от 31. 08.2022 г.
Заведующий МБДОУ «Детский сад №14»
____________________ О.Б. Симонова

# Рабочая программа
# воспитателя по обучению детей татарскому языку
# на 2022/2023 учебный год

**Рассмотрено и принято**
на заседании педагогического совета
протокол № 1 от 31. 08.2022 г.

Юридический адрес: РТ,422980,
г. Чистополь, ул. Г. Тукая,54 «Е»
Телефон: 5-12-04 E-mail: podsolnushekd@mail.ru
Сайт: http:edy.tatar.ru

Чистополь - 2022

## Аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010-2015 елларда мәгарифне үстерү Стратегиясе (30.12.2010, № 1174) - «Киләчәк» программасында мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен Федераль дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирә алырдай укыту - методик комплектлар (УМК) булдыру бурычы куелган. Балалар бакчаларында балаларны татар теленә өйрәтү, аларның сөйләм телен үстерү өчен заман таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән әзлекле, максатчан методик әсбаплар белән тәэмин итү зарур. Әлеге максаттан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карары белән яңа укыту - методик әсбаплар төзелде.

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюҗетлы уеннар оештыру, гомумән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Сөйләшергә өйрәтү өчен баланы мөмкин кадәр күбрәк аралашуга җәлеп итәргә кирәк. Мәктәпкәчә тәрбия учреҗдениеләрнең гомуми белем бирү программасы төзелешенә яңа федераль таләпләр буенча татар теле эшчәнлегенә бирелгән сәгатьләр санын бүлгәндә сөйләм телен үстерүгә күбрәк игътибар итү сорала.

Балалар бакчаларында заманча методик алымнар һәм чаралар куллану, татарча мультфильмнарны, электрон ярдәмлекләрне, аудио һәм видеоматериалларны урынлы файдалану аеруча мөһим.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясендә балалар бакчаларында балаларга татар телен өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне татар теленә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

«Татарча сөйләшәбез» дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма, күрсәтмә һәм таратма әсбәплар, аудио- һәм видеоматериаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелде. Методик комплектлар өч яшь төркеме (уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнде, һәм аларның барысы да «Татарча сөйләшәбез» дип исемләнә. Бүгенге соөиолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту - методик кулланмалар эшләү зарурлыгы килеп басты.

Билгеле булганча, телгә өйрәтүнең максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы - иҗади фикреләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.
Балаларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, балалар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңнау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Баланың сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы** күздә тотыла:

- өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча тәрбияченең сорауларына җавап һәм сораулар куя белү;
- бирелгән үрнәк диалоглар буенча охшаш диалоглар төзү, әңгәмәдә катнаша алу;
- терәк схемалар кулланып, ситуаөия буенча әңгәмә кора белү.

**Телне аралашу аша өйрәнү принцибы.**

Атаклы психологлар А.Н.Леонтьев, П.Я.Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәре үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми. Сөйләмгә өйрәтү проөессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнгеч, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балалрның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лигвистик материал сайлана. Бу процесс түбәндәге схемада күрсәтелә.

## Пояснительная записка

Республика Татарстан - один из многонациональных регионов РФ. Основной задачей государственной политики в сфере дошкольного образования является повышение эффективности и обеспечения общедоступности качественного дошкольного образования для всех слоев населения.

Модернизация Российского образования внесла конструктивные изменения в систему дошкольного образования. На смену традиционным методам организации педагогического процесса ДОУ пришли технологии личностно-ориентированного взаимодействия педагогов с детьми, целесообразной организации развивающей среды, проектно - деятельного и компетентного подходов в организации педагогической работы.

Постановлением кабинета Министров Республики Татарстан от 30.12.2010 г. № 1174 «Об утверждении Стратегии развития образования в Республике Татарстан на 2010-2015 г.г. «Киләчәк» в рамках реализации первоочередных мероприятий Стратегии, творческой группой, созданной Министерством образования и науки Республики Татарстан, разработан учебно-методический комплект по обучению детей двум государственным языкам в дошкольных образовательных учреждениях Республики Татарстан.

Творческая группа под руководством З.М Зариповой разработала УМК по обучению русскоязычных детей татарскому языку. Проект состоит из трех частей: «Минем өем» (для средней группы), «Уйный-уйный үсәбез» (для старшей группы), «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар» (для подготовительной к школе группы).

Одна из актуальных проблем в системе образования - это вопрос об овладении вторым языком. Хорошее владение татарским языком как средством общения - веление сегодняшнего дня: оно необходимо не только для успешной учебы в школе, но и для интеллектуального и нравственного становления детей дошкольного возраста.

Особенности овладения вторым языком в дошкольном возрасте связаны с непосредственностью детского восприятия, открытостью по отношению к людям, говорящим на другом языке. Ребенок дошкольного возраста не осознает, зачем ему нужно знать второй язык, мотивация дошкольников действует по принципу «здесь и теперь», то есть ребенок не задается отдаленными целями.

Основной задачей изучения татарского языка в дошкольном возрасте является формирование первоначальных умений и навыков практического владения татарским языком в устной форме.

Формировать мотивацию учения ребенка, активизировать в речи слова обозначающие предмет, признак предмета и действие; способствовать умению составлять небольшие рассказы по серии ситуативных картинок с одним действующим лицом, сюжетной картине или из личных наблюдений ребенка.

В процессе обучения дети должны научиться воспринимать и понимать татарскую речь на слух и говорить по-татарски в пределах доступной им тематики, усвоенных слов.

Рабочая тетрадь является одним из основных компонентов УМК «Говорим по-татарски», предназначенных для детей 4-7 лет, делающие первые шаги в мир татарского языка. Творческая тетрадь поможет: ребенку усвоить лексику татарского языка, закрепить речевой материал, привлечь родителей активно включиться в процесс развития своего малыша. В рабочей тетради даны задания на обозначение словом, обобщение и сравнение предметов на определение их величины, размера, количества.

Программа направлена на развитие устойчивого интереса к татарскому языку, на автоматизацию речевой активности детей.

## Лингвистик материал сайлау схемасы
## Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау
## Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү
## Сөйләм бурычларын ачыклау
## Тиешле лингвистик материалны сайлау

Әлбәттә, эчтәлек сайлаганда сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен балаларның психо-физиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур. Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал балалар бакчасында телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

**Телне өйрәнү процессын индивидуальләштерү принцибы.**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү проөессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану - тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Материалны кат - кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик - грамматик материалны балаларның мөстәкыөль комбинаөияләп сөйләшү - тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә  балалар тел өйрәнүнең  практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан  булуын тәэмин ителә. Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу - телне үзләштерү процессын жиңеләйтә. Димәк, һәр шөгыльгә программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Шөгыльләрдә ситуатив күнегүләрнең рус һәм татар телендә бирелүе, балаларның белем  сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

Комплектларның төп максаты балаларны аралашуга өйрәтү.

**Укыту методик кулланма (УМК) өч проекттан тора һәр проект өчен:**

1) тематик план;
2) календарь – көндәлек план;
3) балалар өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоматериаллар;
5) мультипликацион сюжетлар;
6) күрсәтмә, таратма материаллар исемлеге;
7) диагностика төзелде.

**Беренче проект «Минем өем»**

4-5 яшьлек балалар (уртанчылар төркеме) өчен.

**Икенче проект «Уйный-уйный үсәбез»**

5-6 яшьлек балалар (зурлар төркеме) өчен.

**Өченче проект «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар»**

6-7 яшьлек балалар (мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен.

**«Минем өем» проекты**

**Максат:** Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.
**Бурычлар:** 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**«Уйный-уйный үсәбез» проекты**

**Максат:** Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.
**Бурычлар:** 1. Сүз байлыгы арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмүлүрен тәрбияләү.

**«Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар» проекты**

**Максат:** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.
**Бурычлар:** 1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мәрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**«Минем өем» проекты:**
1. Аудиоматериал – 64 кисәк (ТРЭК)
2. Мультипликацион сюжет – 11 данә
3. Эш дәфтәре – 17 бирем
4. Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде)
5. Актив сүзләр + сөйләм үрнәге – 62

**«Уйный-уйный үсәбез» проекты:**
1. Аудиоматериал – 63 кисәк (ТРЭК)
2. Мультипликацион сюжет – 15 данә

3. Эш дәфтәре – 19 бирем
4. Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде)
5. Актив сүзләр + сөйләм үрнәге – 45(107)

**«Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар» проекты:**

1. Аудиоматериал – 71 кисәк (ТРЭК)
2. Мультипликацион сюжет – 19 данә
3. Эш дәфтәре – 20 бирем
4. Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде)
5. Актив сүзләр + сөйләм үрнәге – 60 (167)

| №П/П | ЯШЬ АРАЛЫГЫ | АКТИВ (пассив) СҮЗЛӘР | СҮЗЛӘР САНЫ |
|---|---|---|---|
| 1. | 4-5 яшь | **Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә?, нинди? (13 сүз) | **62 сүз** |
| 2. | 5-6 яшь | **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз) | **45 сүз** |
| 3. | 6-7 яшь | **Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли? Йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?, сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк – чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, жырла, жырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр. (58 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** нәрсә яратасың? (2 сүз) | **60 сүз** |

**Тәрбиячеләр өчен язылган методик кулланмага:**

1. Тематик план
2. Шөгыльләр конспекты
3. Диагностика кертелде

**Бу укыту методик кулланмалар нәрсә белән аерыла соң?**

Бүгенге көндә балаларны татар теленә өйрәткәндә кулланыр өчен эш дәфтәрләре, аудиоматериаллар, мультипликацион сюжетлар булмады. Без өч төркем өчен дә эш дәфтәрләре ясадык. Аларның эчтәлеген, биремнәрен, нинди рәсемнәр куллануны уйлап. Аудиоматериал, мультипликацион сюжетларның эчтәлеген шөгыльләргә туры китереп эшләдек.

Эш дәфтәрләре, аудиоматериал һәм мультипликацион сюжетлар һәр шөгыльдә дә кулланылмый. Кулланылган очракта шөгыльнең бер өлеше булып бара.

**Мультипликацион сюжетлар** өченче шөгыльдә карау өчен уйлап эшләнелде. Эчтәлеге 3-7 минут алар балаларның белгән сүз байлыгына яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алып төзелде. Берничә шөгыль узгач өйрәнгән сүзләр һәм алдагы шөгыльләрдә сйөләмдә куллануга кертелә торган яңа сүзтезмәләр дә кулланылды. Бу мультипликацион сюжетларны караганнан соң балалар белән сорау – җавап тибында әңгәмәләр үткәрелә, вакыт калса алда өйрәнелгән уеннарны кабатларга тәкъдим ителә.

**Аудиоматериаллар:** танышу, яңа сүз, өйрәткәндә, диалог, сөйләм үрнәкләре, уеннар, кыска җырлар, өстәл театры күрсәткәндә куллану өчен төзелде.

**Эш дәфтәрләре** шөгыльдә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелде. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер – берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Бик уңай ягы, балалар үзләренең шөгыльдә эшләгән дәфтәрләрен өйгә алып кайтып кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән эти – әниләр дә, төркемдә эшләгән тәрбиячеләр дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылды.

Педагогика багышланган әдәбиятне карап чыкканнан соң, нинди дә булса бер чараны гына алып, менә монысы гына тел өйрәнү өчен иң куәтлесе, иң кирәклесе дип берсен генә аерып әйтеп булмый. Һәрбер автор төрле чараны атый.

Һәм шуңа да, укыту – методик комплектның юнәлешләре күптөрле. Алар балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп эшләнде. Һәрбер юнәлеш билгеле бер үзенең максатын чишә. Билгеләп үтелгәнчә, гамәли дәфтәрләр, яки эш дәфтәрләре – заманча төзелгән укыту – методик комплектының төп юнәлешләренең берсе булып тора.

Заман үзенең таләпләрен алга китереп куйды, инде математика, сөйләм үстерү һ.б. шөгыльләрдә балалар белән эшләү өчен дәфтәрләрне күптән кулланса лар да, татар теле өйрәтүдә бу яңа чара буларак кабул ителә.

Дәфтәрләр балаларның педагог тарафыннан оештырылган эшчәнлектә алган белемнәрен ныгыту максатында куллану өчен тәкъдим ителә.

Эш дәфтәрнең дидактик функөияләре:

1. Компенсаторная (компенсатор) – яки бу балаларга сүз өйрәтү процессын җиңеләйтү, баланың һәм тәрбияченең көчен һәм вакытын экономияләү дигән сүз. Менә бит эле без ниндидер дәрәҗәдә сәламәтлек саклау аспектына да кагылып китәбез икән. Тәрбияче белән балалар күмәк эшли, ә балалар исә эшчәнлек төрен үзгәртәләр.
2. Информативная (информатив) – яки балалар өчен иң кирәкле информацияне җиткерү.
3. Интегративная (интегратив) – өйрәнү объектын өлешләп һәм бербөтен итеп карау.
4. Познавательная (танып – белү) – баланың танып – белүен үстерү, яки күзәтүчәнлек, уйлау, эстетик матурлыкны күрә белүе.
5. Формирующая ( формалаштыру) – баланың материалны үзләштерүе, танып – белү алымнары формалашуы.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны узара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән. Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этщрщбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2 – нче зат алмашлыгына тәңгәл формала ( яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1 – нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм). Шулай ук балалар күп кенә сораулар куярга өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3 – 4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа һ.б. Балалар  бакчасы булгач, әкият геройлары, җәнлекләр тулаем кеше тормышындагы хәлләрне кабатлыйлар. Чөнки кешегә генә кайтарып калдырсаң, гел әни йоклый, бабай укый, кыз юына кызык түгел. Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына әзерләнгән биремнәрнең өченчесе җыр булып бара. Балалар өйрәнгән сүзләрен кабатлап җырлап та куялар.

Нинди дә булса кузаллау булсын өчен, эш дәфтәрләре интерактив тактага ясалган. Гомумән, интерактив такта булган бакчалар өчен бу биремнәрне тактага күчерергә тәкъдим ителә, чөнки бу очракта,  дәфтәрләрне балаларның үзләренә бирергә мөмкинлек туа, алар өйләрендә әти – әниләре белән бергәләп эшли алалар.

Дәфтәр китап кибетләре киштәләренә чыккан очракта, ата – аналар һәм төркем тәрбиячеләрен искә алып, куллану мөмкинлеге күбрәк булсын өчен биремнәр русча язылды.

Укыту – методик кулланмага таянып ТНВ каналы «Әкият илендә» дигән тапшыру эшләде. Ул шимбә көнне 9.30 минутта ТНВ каналыннан күрсәтелә башлады.

## Тематические мероприятия (праздники, развлечения)

| № | Мероприятия | Дата проведения |
|---|---|---|
| 1. | Сөмбелә бәйрәме | Октябрь |
| 2. | Неделя родного языка «Язык родной, дружу с тобой!» | Февраль |
| 3. | Нәүрүз, Карга боткасы | Март |
| 4. | Литературная викторина по произведениям Г. Тукая для дошкольных групп, приуроченная к дню рождения поэта | Апрель |
| 5. | Сабантуй | Июнь |

## Уртанчылар төркеме

| № | Темалар | Сәгәтъ |
|---|---|---|
| **1.** | **Гаилә-Семья** | **33** |
| | Вводные темы | 6 |
| | «Минем гаиләм» | 1 |
| | «Малай, кыз» | 1 |
| | «Минем туганнарым» | 1 |
| | «Минем гаиләм» **(кабатлау)** | 2 |
| | «Минем туганнарым» **(кабатлау)** | 1 |
| | «Әйдәгез, танышыйк» | 2 |
| | «Тату гаилә» | 1 |
| | «Әйдәгез, танышыйк» | 3 |
| | «Минем дуслар» | 2 |
| | «Эйдәгез, дуслашыйк» **- мультфильм** | 1 |
| | «Әйе, юк» | 2 |
| | «Качышлы уйныбыз» **- мультфильм** | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Кунак килгән» | 2 |
| | «Әйдәгез, уйныйбыз» | 1 |
| | «Кунак килгән» | 2 |
| | «Әйдәгез, уйныйбыз» | 1 |
| | «Безнең кунаклар» | 2 |
| | «Шалкан әкияте» **- мультфильм** | 1 |
| **2.** | **Ашамлыклар - Продукты питания** | **15** |
| | «Әби күчтәнәче» | 1 |
| | «Бабай күчтәнәче» | 1 |
| | «Безнең кунаклар» **- мультфильм** | 1 |
| | «Сөт, чәй» | 1 |
| | «Дустыңны сайла» | 2 |
| | «Рәхмәт әйт» | 1 |
| | «Дустыңны сайла» | 1 |
| | «Рәхмәт әйт» | 1 |
| | «Песине сыйла» | 1 |
| | «Кунак сыйлау» | 1 |
| | «Тәмле» кибетендә **- мультфильм** | 1 |
| | «Кунакны ашат» | 1 |
| | «Чәй табынында» | 1 |
| | «Азат кунак чакыра» **- мультфильм** | 1 |
| **3.** | **Уенчыклар-Игрушки** | **27** |
| | «Уенчыклар» | 1 |
| | «Зур, кечкенә» | 1 |
| | «Күңел ачу кичәсе «Туган көн»» | 1 |
| | «Курчак кунакка килгән » | 1 |
| | «Уенчыклар кибете» | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Курчак кунакка килгән» | 1 |
| | «Уенчыклар кибете» | 1 |
| | «Паркка сәяхәт» **- мультфильм** | 1 |
| | «Яңа уенчыклар» | 1 |
| | «Уйныйбыз» | 1 |
| | «Без уйнарга яратабыз» | 1 |
| | «Яңа уенчыклар» | 1 |
| | «Уйныйбыз» | 1 |
| | «Алсуның туган көне» | 1 |
| | «Мияуга бүләк» | 1 |
| | «Уенчыклар кибете» | 1 |
| | «Уенчыклар үпкәләгән» **- мультфильм** | 1 |
| | «Бүләкләр» | 1 |
| | «Уйна» | 1 |
| | «Күңелле уеннар» **- мультфильм** | 1 |
| | «Уенчыклар юабыз» | 1 |
| | «Уенчык ю!» | 1 |
| | «Акбай һәм мияу маҗаралары» **- мультфильм** | 1 |
| | «Уенчыклар юабыз» | 1 |
| | «Уенчык ю!» | 1 |
| | «Пычрак-чиста» | 1 |
| **4.** | **Саннар-Числа** | **9** |
| | «Саннар» | 2 |
| | «Уйныйбыз да, саныйбыз да» | 1 |
| | «Уенчыклар» | 1 |
| | «Ничә уенчык?» | 1 |
| | «Уйный – уйный саныйбыз» **- мультфильм** | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Уенчыклар» | 1 |
| | «Ничә уенчык?» | 1 |
| | «Уйныйбыз да, саныйбыз да» | 1 |
| 5. | **Кабатлау** | **27** |
| | «Бергәләп уйныйбыз» | 1 |
| | «Кунак чакырабыз» | 1 |
| | «Күңелле ял итәбез» **- мультфильм** | 1 |
| | «Без татарча сөйләшәбез» | 1 |
| | «Бу өйдә кем яши?» | 1 |
| | «Без театр уйныйбыз» | 1 |
| | «Бу өйдә кем яши?» | 1 |
| | Без театр уйныйбыз» | 1 |
| | «Без татарча сөйләшәбез» | 1 |
| | «Бу өйдә кем яши?» | 1 |
| | «Без татарча сөйләшәбез» | 1 |
| | «Ягымлы сүзләр» | 1 |
| | «Хелләр ничек? » | 1 |
| | «Кунак сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Ипи, алма, сөт, чәй» | 1 |
| | «Кунак сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Зур, кечкенә» | 1 |
| | «Кунак сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Минем өем» | 2 |
| | «Бу өйдә кем яши?» | 1 |
| | «Минем өем» | 1 |
| | «Уйныйбыз» | 1 |
| | «Уйный – уйный саныйбыз» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Хелләр ничек? » | 1 |
| | «Минем өем» | 1 |
| | «Хелләр ничек? » | 1 **(111 сәг.)** |

## Зурлар төркеме

| № | Темалар | Сәгатъ |
|---|---|---|
| **1.** | **Мой дом-Минем өем** проекты буенча. | **6** |
| | «Гаилә» (кабатлау) | 1 |
| | «Ашамлыклар» (кабатлау) | 1 |
| | «Уенчыклар» (кабатлау) | 1 |
| | «Минем өем» | 1 |
| | «Кем юк?» | 1 |
| | «Шалкан» әкияте» **- мультфильм** | 1 |
| **2.** | **Яшелчәләр-Овощи** | **23** |
| | «Кишер үстерәбез» | 2 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№1 “Гаилә”) **- кабатлау** | 1 |
| | «Куян күчтәнәче» | 2 |
| | «Баллы кишер» **- мультфильм** | 1 |
| | «Серле кәрзин» | 1 |
| | «Сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Бар матур бакча» | 1 |
| | «Серле янчык» | 1 |
| | «Серле кәрзин» | 1 |
| | «Бар матур бакча» | 1 |
| | «Без хезмәт яратабыз» | 1 |
| | «Яшелчәләр кибете» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Уйный - уйный эшлибез» **- мультфильм** | 1 |
| | Төсләр дөньясы | 2 |
| | «Юл мажаралары» **- мультфильм** | 1 |
| | «Яшелчә салаты» | 1 |
| | «Яшелчә ю» | 1 |
| | «Яшелчәләр кибете» | 1 |
| | «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да» | 1 |
| | «Уңыш бәйрәме» | 1 |
| **3.** | **Ашамлыклар-Продукты** | **11** |
| | «Ашамлыклар» | 1 |
| | «Ашханә» | 1 |
| | «Аш бүлмәсе» **- мультфильм** | 1 |
| | Төсләр дөньясы **- кабатлау** | 1 |
| | «Аю кунакка килгән» | 1 |
| | «Ашханә» | 1 |
| | «Яшелчәләр» кибетендә**- кабатлау** | 1 |
| | «Аю кунакка килгән» | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | «Яшелчәләр» кибетендә **- кабатлау** | 1 |
| | «Ашамлыклар» кибетендә | 1 |
| **4.** | **Савыт-саба-Посуда** | **12** |
| | «Туган көн» | 1 |
| | «Курчак Алиягә булыш» | 1 |
| | «Өч аю» - мультфильм | 1 |
| | «Чәй табыны әзерлибез» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Тәсле чынаяклар» | 1 |
| | «Чисталыкта матурлык» - **мультфильм** | 1 |
| | «Уенчыклар» кибетендә - **кабатлау** | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | «Курчак Алиягә булыш» | 1 |
| | «Тәсле чынаяклар» | 1 |
| | «Чәй табыны әзерлибез» | 1 |
| | «Туган көн» | 1 |
| **5.** | **Киемнәр-Одежда** | **4** |
| | «Туган көнгә яңа киемнәр» | 1 |
| | «Курчакны киендер» | 1 |
| | «Без киенәбез» | 1 |
| | «Киенергә ярдәм ит» | 1 |
| **6.** | **Шәхси гигиена** | **18** |
| | «Алия йокларга җыена» | 1 |
| | «Курчакны чишендер» | 1 |
| | «Киенергә ярдәм ит» | 1 |
| | «Шаян уенчыклар» - **мультфильм** | 1 |
| | «Аю кунакка килгән» - **кабатлау** | 1 |
| | «Хәерле көн» | 1 |
| | «Туган көнгә яңа киемнәр» - **кабатлау** | 1 |
| | «Чәй табыны әзерлибез» | 1 |
| | «Алия йокларга җыена» | 1 |
| | «Хәерле көн» | 1 |
| | «Чәй табыны әзерлибез» - **кабатлау** | 1 |
| | «Курчак белән уйныйбыз» - **кабатлау** | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Шаян уенчыклар» **- мультфильм** | 1 |
| | «Ни өчен киемнәр югалган?» **- мультфильм** | 1 |
| | «Курчак белән уйныйбыз» **- кабатлау** | 1 |
| | «Киенергә ярдәм ит» | 1 |
| | «Алия йокларга җыена» | 1 |
| | «Хәерле көн» | 1 |
| **7.** | **Өй җиһазлары-Мебель** | **4** |
| | Өстәл театры «Өч аю» | 1 |
| | «Җиһазлар кибете» | 1 |
| | «Маша һәм өч аю» **- мультфильм** | 1 |
| | «Җиһазлар кибете» | 1 |
| **8.** | **Бәйрәм «Туган көн»-Праздник «День рождения»** | **20** |
| | «Уенчыклар иленә сәяхәт» | 1 |
| | «Курчакның туган көне» | 1 |
| | «Туган көн» - **мультфильм** | 1 |
| | «Уйнарга яратабыз» | 1 |
| | «Син нәрсә яратасың?» | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» **- мультфильм** | 1 |
| | «Уйный-уйный үсәбез» | 1 |
| | «Уенчыклар иленә сәяхәт» | 1 |
| | «Курчакның туган көне» | 1 |
| | «Туган көн» - **мультфильм** | 1 |
| | «Нәрсә бар?» | 1 |
| | «Бар, юк» | 1 |
| | «Нәрсә бар?» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Син нәрсә яратасың?» | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | «Нәрсә бар?» | 1 |
| | «Бар, юк» | 1 |
| | «Маша һәм өч аю» **- мультфильм** | 1 |
| | «Хәерле көн» **- кабатлау** | 1 |
| | «Нәрсә бар?» | 1 |
| **9.** | **Бәйрәм «Сабантуй»-«Праздник Сабантуй»** | **7** |
| | «Сабантуйга әзерләнәбез» | 1 |
| | «Сабантуй» исемле мультфильм карау («Татармультфильм» студиясе) | 2 |
| | «Күңелле Сабантуй уеннары» | 1 |
| | «Сабантуйга әзерләнәбез» | 1 |
| | «Сабантуй бәйрәме» | 1 |
| | «Сабантуйга әзерләнәбез» | 1 |
| **10.** | **Кабатлау** (Төсләр, Ашамлыклар, Киемнәр, Өй җиһазлары) | **5** **(110 сәг.)** |

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

| **№** | **Темалар** | **Сәгәть** |
|---|---|---|
| | **Кабатлау** | **2** |
| | «Әйдәгез танышабыз» | 1 |
| | «Хәерле көн» | 1 |
| | «Мияу адашкан» **-мультфильм** | 1 |
| | «Син кем?» | 1 |
| | «Шалкан» әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| | «Аю баласы дөнья белән таныша» **- мультфильм** | 1 |
| | «Бу нәрсә?» | 1 |
| | «Кем нишли?» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Батыр Мияу белән куркак Куянкай» **- мультфильм** | 1 |
| | «Бу нәрсә?» | 1 |
| | «Кем нишли?» | 1 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№ 2 “Хәрәкәтләр”) | 1 |
| | «Дусларны сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Нишлисең?» | 1 |
| | «Тату гаилә» **- мультфильм** | 1 |
| | «Кем нишли?» | 1 |
| | «Дусларны сыйлыйбыз» | 1 |
| | «Әйдәгез уйныйбыз» | 1 |
| | «Кунак килде» | 2 |
| | «Юмарт аю» **- мультфильм** | 1 |
| | «Әйдәгез уйныйбыз» | 1 |
| | «Кунак килде» | 1 |
| | «Кафега барабыз» | 1 |
| | «Без кафеда» | 1 |
| | «Кафега барабыз» | 1 |
| | «Кафега барабыз» **- мультфильм** | 1 |
| | «Без кафеда» | 1 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№ 3 “Кафега барабыз ”) | 1 |
| | «Күңелле уеннар» | 3 |
| | «Күңелле уеннар» **- мультфильм** | 1 |
| | «Спорт бәйрәменә әзерләнәбез» | 1 |
| | «Бәйрәмгә барабыз» | 1 |
| | «Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» **- мультфильм** | 1 |
| | «Казанда спорт бәйрәме» | 2 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№ 10 “Нишлисең? Нишли?”) | 1 |
| | «Без циркта» | 2 |
| | «Җәнлекләр спорт бәйрәмендә» **- мультфильм** | 1 |
| | «Безнең дуслар» | 1 |
| | «Үрдәк дусларын тапты» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | «Циркта» **- мультфильм** | 1 |
| | «Безнең дуслар» | 2 |
| | «Кунак килде» | 1 |
| | «Безнең дуслар» | 1 |
| | «Чукмар белән Тукмар» А.Алиш **- мультфильм** | 1 |
| | «Акбай чана шуа» | 1 |
| | «Чана шуам» | 1 |
| | «Тауда» | 3 |
| | «Шаян кошлар» **- мультфильм** | 1 |
| | «Әйдә, бие» | 2 |
| | «Без биибез» | 4 |
| | «Урманда зур концерт» **- мультфильм** | 1 |
| | «Мияуның бүлмәсен бизибез» | 1 |
| | «Туган көнгә бүләк әзерлибез» | 1 |
| | «Акбай туган көнгә барырга әзерләнә» **- мультфильм** | 1 |
| | «Туган көнгә әзерләнәбез» | 3 |
| | «Мияуның туган көне» | 1 |
| | «Туган көн табынында» | 1 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№11 “Төсләр”) | 1 |
| | «Мияуның туган көне» | 2 |
| | «Әкият илендә» тапшыруын карау (№ 6 “Бие, җырла”) | 1 |
| | «Күңелле сәяхәт» | 2 |
| | «Урман китапханәсендә» **- мультфильм** | 1 |
| | Күңелле сәяхәт» | 2 |
| | «Уйный-уйный укыйбыз» **- мультфильм** | 1 |
| | «Мәктәптә» | 1 |
| | «Уку бүлмәсе» | 1 |
| | «Урман мәктәбендә» **- мультфильм** | 1 |
| | «Портфельдә нәрсә бар?» | 1 |
| | «Нәрсә кирәк?» | 1 |
| | «Нәрсә? Нинди? Ничә?» | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Өстәл театры «Теремкәй» | 1 |
| | «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| | «Теремкәй» **- мультфильм** | 1 |
| | Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| | «Кем нәрсә ярата?» **- мультфильм** | 1 |
| | «Белем иленә сәяхәт» | 1 |
| | «Могҗизалар кыры» | 1 |
| | «Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар» | 1 |
| | **Кабатлау** | **11** |
| | Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | «Белем иленә сәяхәт» | 2 |
| | «Могҗизалар кыры» | 1 |
| | «Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар» | 1 |
| | «Татарча сөйләшәбез» | 1 |
| | «Могҗизалар кыры» | 1 |
| | «Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар» | 1 |
| | «Татарча сөйләшәбез» | 1 |
| | «Могҗизалар кыры» | 2 **(109 сәг.)** |

## Система мониторинга результатов обучения детей татарскому языку

Педагогическое обследование проводится два раза в год: в первое полугодие и во второе полугодие.

| | **БЕРЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ** | **ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ** | **УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ** | **ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ, МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ** |
|---|---|---|---|---|
| Уку елы башында | | | | + |
| Уку елы ахырында | | | + | + |

## Диагностика

Түбәндәге биремнәрне балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләгәндә кулланырга мөмкин. Тикшерү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 – 10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, тикшерүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда тикшерүче елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмаган очракта, булышырга тиеш.

Тикшерү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.

Нәтиҗәгә карап, тәрбияче, һәр бала белән эшләү өчен, бурычлар билгели.

## Диагностический инструментарий

**<u>Уртанчылар төркеме (средняя группа)</u>**

Уку елы ахырына балалар түбәндәге белемнәрне үзләштерергә тиешләр

(К окончанию учебного года ребенок должен знать и уметь):

1. Бу кем? Бу нәрсә? Нинди? Ничә? сорауларына җавап бирергә.
2. Исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белергә.
3. Гади биремнәрне үти алырга: бир, мә, кил монда, утыр, сикер, аша, эч, ю, уйна.
4. Әйберләрнең билгесен белдерә торган сүзләрне белергә: зур, кечкенә, матур, чиста, пычрак, әйбәт, тәмле.
5. Бишкә кадәр саный белергә.
6. Мин, син, бу, монда алмашлыкларын кулланырга.
7. Дүртюллыклар, җырлар өйрәнергә.
8. Раслаучы сүзләрне: әйе; инкарь итүче: юк аңнлап кулана белергә.
9. Ел ахырына сүзләр саны - 62 сүз.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының**
**«Минем өем» проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү**

| | | Сүз байлыгы (лексика) | | Бәйләнешле сөйләм (связная речь) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **№** | | «Минем өем» проекты буенча өйрәнгән | Ягымлы сүзләр куллану («исәнме», | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана | Тирә - юньдәге предметларның | Аралаша белү (ягымлы сүзләр |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | «сау бул», «рәхмәт») | белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | сыйфатын, күләмен белдерә торган сәзләрне аңлап сөйләмдә куллану | әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкьдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2, 7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша (ребёнок активен в общении, отвечает на вопросы, идет на контакт) |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2, 6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел (лексический запас имеется, не проявляет активность в общении) |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә (понимает, но отвечает по - русски) |

**Зурлар төркеме (старшая группа)**

Уку елы ахырына балалар түбәндәге белемнәрне үзләштеррергә тиешләр
(К окончанию учебного года ребенок должен знать и уметь):
Бу кем? Бу нәрсә? Нинди? Ничә? сорауларына өстәп, Кем анда? Кем юк? Син кем? Нәрсә кирәк? Нәрсә бар? сорауларына аңлап җавап бирергә.
Раслаучы сүзләрне: әйе, бар; инкарь итүче; юк аңлап куллана белергә.
Тәрбияче кушкан биремнәрне аңлап үтәргә (мә, бир, ал, утыр, сана, аша, эч, сал, ки, йокла, җырла).
Матур итеп исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белергә.
Балалар үзләре сорау куярга, гади диалогларда үзләрен ышанычлы сизеп сөйләшә белергә.
Төп хәрәкәтләрне белдерүче фигыльләрне аңлый һәм куллана белергә тиешләр (сикерә, уйный, җырлый, юа, ашый, эчә, ярата, кия, сала, утыра).
Әйберләрнең билгесен белдерә торган сүзләрне белергә.
Төсләр: кызыл, сары, яшел, зәңгәр.
Тәм: тәмле, баллы.
Зурлык: зур, кечкенә, күп, әз.

Билге: матур, чиста, пычрак,әйбәт.
8. 10 га кадәр саный белергә.
9. Предметның урынын күрсәтергә: караватта, өстәлдә, урындыкта.
10. Грамматик конструкцияләре, гади җөмләләр төзергә.
11. Дүртюллыкларны, җырларның сүзләрен яттан өйрәнергә, сәхнәләштерүдә катнашырга.
12. Ел ахырына сүзләр саны - 62+ **45** =107 сүз.

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме баларның «Уйный-уйный үсәбез» проекты буенча татар телен үзләштерә дәрәҗәләрен билгеләү**

| | | Сүз байлыгы (лексика) | | Бәйләнешле сөйләм (связная речь) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **№** | | «Уйный-уйный үсәбез» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш-алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану («исәнме», «сау бул», «рәхмәт», «исәнмесез», «сау булыгыз») | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (нәрсә кирәк? нинди? ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2, 7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша (ребёнок активен в общении, отвечает на вопросы, идет на контакт) |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2, 6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел (лексический запас имеется, не проявляет активность в общении) |
| Уртачадан түбән дәрәҗә | Аңлый, русча җавап бирә (понимает, но отвечает по - русски) |

| | |
|---|---|
| 1 дән 2 гә кадәр | |

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча татар телен үзләштерә дәрәҗәләрен билгеләү (подготовительная к школе группа)**

| | | **Сүз байлыгы (лексика)** | | **Бәйләнешле сөйләм (связная речь)** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **№** | **Баларның исем, фамилиясе** | «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану («исәнме», «исәнмесез», «сау бул», «сау булыгыз», «рәхмәт», «зур рәхмәт», «хәерле көн», «хәлләр ничек?», «әйбәт») | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү (нәрсә кирәк? нинди? ничә? син кем? бу кем? бу нәрсә? нишли? кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкьдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |
| 3. | ... | | | | | |
| 4. | ... | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2, 7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша (ребёнок активен в общении, отвечает на вопросы, идет на контакт) |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2, 6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел (лексический запас имеется, не проявляет активность в общении) |

| | |
|---|---|
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә (понимает, но отвечает по -  русски) |

## Литература:


1. Закирова К.В. «Балачак -  уйнап-көлеп үсәр чак»: Казан, 2012.
2. Закирова К.В.  «Балачак аланы»: Казань, 2011.
3. Закирова К.В.  «На поляне детства»: Казань, 2011.
4. Закирова К.В. «Иң матур сүз»: Казан, 2000.
5. Зарипова З.М. и др. «Планирование деятельности по обучению дошкольников татарскому языку. Методическое пособие» - Казань : Татарское республиканское издательство «ХЭТЕР», 2018. - 171 б.
6. Зарипова З. М. «Татарча сөйләшәбез» («Говорим по-татарски»): Казань, 2012 г.
7. Зарипова З. М.  «Татарча сөйләшәбез» - Эш дәфтәре (Рабочая тетрадь): Казан, 2012.
8. «Татар теле өйрәнә нәниләр»: Казан, 2005.
9. Шаехова Р.К. «Региональная программа дошкольного образования»: Казань, 2011.
10. Шаехова Р.К. «Сөенеч - Радость познания: регионально - образовательная программа дошкольного образования»: Казань, 2016.
11. Шаехова Р.К. «Раз - словечко два словечко»: Казань, 2013.
12. Шаехова  Р.К.  «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр алифбасы»: Казан, 2011.
13. Ягофаров Р.Ф. «Татар халык уеннары»: Казан, 2002.